# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Җир өчен түләү турында" Татарстан
Республикасы Законына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү хакында

1. "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 статья. 6 статьяның беренче өлешендәге: "... әмма минималь хезмәт хакының 0,001 процентыннан артмаска тиеш" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

2 статья. 9 статьяның беренче өлешендәге: "су электрстанцияләренең сусаклагычларын", "информатика һәм Галәм тәэминаты җирләре өчен, хакимият һәм идарә органнарының, Коралды көчләренең, эчке һәм тимер юл гаскәрләренең, Галәм системаларының эшчәнлеген тәэмин итүгә бирелгән җирләр өчен " дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

3 статья. 10 статьядагы: "су электрстанцияләренең сусаклагычларыннан гайре" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

4 статья. 12 статьяның 2 пунктындагы "...һәм укыту-тәҗрибә хуҗалыклары, фәнни-тикшеренү учреждениеләре һәм уку йортлары" дигән сүзләрне "...фәнни-тикшеренү учреждениеләренең һәм уку йортларының укыту-тәҗрибә хуҗалыклары" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

5 статья. 12 статьяның 3 пунктындагы "физик тәрбия һәм спорт, мәдәният,...турист һәм спорт-савыктыру комплекслары" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

6 статья. 12 статьяга түбәндәге эчтәлектә 11,12,13,14 пунктлар өстәргә:

11) финанс чыганакларына карамастан, мәдәният, физик тәрбия һәм спорт, туризм, спорт-савыктыру юнәлешендәге учреждениеләр һәм спорт корылмалары (эшчәнлеге спортка һәм физик тәрбия-савыктыруга юнәлтелмәгән корылмалардан, учреждениеләрдән гайре);

12) телевидение һәм радиотапшыруларның дәүләт программалары таралышын (трансляциясен) тәэмин итүче, шулай ук саклану, мәгълүмат һәм Галәм тәэминаты мәнфәгатьләрендә эшчәнлек алып баручы элемтә предприятиеләре һәм объектлары;

13) дәүләт хакимияте, идарәсе органнары, саклану һәм хөкем органнары;

14) гарипләрнең җәмәгать оешмалары милкендәге предприятиеләр.

7 статья. 19 статьядагы "30 процент" дигән сүзләрне "50 процент" дип үзгәртергә.

II. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 21 июле
№2198-XII